**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КЕЧЕ ШИЛНӘ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ Б**
**ЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«19» ноябрь 2021 ел № 10/2

**«Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 28 сентябрендәге 32/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394 һәм 397 статьялары, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 28 сентябрендәге 32/1 номерлы карарына (2018 елның 16 январендәге 34/4 номерлы, 2018 елның 16 октябрендәге 44/2номерлы, 2019 елның 20 ноябрендәге 8/3 номерлы, 2020 елның 4 июндәге 2/4 номерлы, 2021 елның 22 апрелендәге 2/1 номерлы, 2021 елның 21 октябрендәге 9/3 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка пуктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе А.Г. Даутов